***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

# БИРЕМНӘРЕ

(2024-2025 нче уку елы)

**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [э] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Дөрес эш өчен кыю басып тор.* (Мәкаль)
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   в) 4

2. Кече тел тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [һ]
   ә) [й]
   б) [ф]
   в) [х]

3. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аңлатасың
   ә) аңлаталар
   б) аңлаттылар
   в) аңлатмадылар

4. Антонимнарны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кача, яшеренә
   ә) уйный, шаяра
   б) кайгыра, шатлана
   в) яна, балкый

5. Фразеологизмның синоним парын билгеләгез. **(2 балл)**
   ***түшәмгә төкереп яту***
   а) стенага борчак ату
   ә) корыны бушка аудару
   б) тетмәсен тетү
   в) сабын куыгы очыру

6. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) шат, таш

ә) күл, күлмәк
б) бүл, бүлмә
в) кискеч, бетергеч

7. Тартым белән төрләнгән исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) кош
ә) кошчык
б) кошларга
в) кошчыгым

8. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) якты
ә) яктырак
б) яп-якты
в) уттай

9. Җөмләдәге фигыльнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Аю – көченә, кеше акылына ышана.* (Мәкаль)
а) хәзерге заман хикәя фигыль
ә) үткән заман хикәя фигыль
б) киләчәк заман хикәя фигыль
в) боерык фигыль

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Яңа ел бәйрәмен балалар шатланып көтеп алалар.* (Мәкаль)
а) Яңа ел
ә) бәйрәмен
б) балалар
в) көтеп алалар

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар телендә авыз һәм _____________ тартык авазлар була. Сүзләрнең мәгънәләре _____________ сүзлекләрдә күрсәтелә. Күп мәгънәле сүзләрнең туры һәм _____________ мәгънәләре була. Сүзнең _____________ тамырдан яки тамыр һәм ясагыч кушымчадан тора. -ның/-нең – _____________ килеше кушымчасы. Без, сез, алар – _____________ алмашлыклары. Хикәя фигыльләр зат-_________ белән төрләнәләр. Ия һәм _____________ – җөмләнең баш кисәкләре.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**
*сүзеннән, кешенең, начардан, билгеле, холкы, качар, акылы, дуслары*

______________________________________________________________

______________________________________________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
Меня зовут Елизавета. ________________________________________________
Я приехала из Москвы. _______________________________________________
В школе изучаем татарский язык. _____________________________________
На уроке мы часто читаем вслух. ______________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

КОЯШЛЫ УЕНЫ

Яуды яңгыр, яуды яңгыр,
Күлләвекләр җыелды.
Чулт-чулт итеп агачлардан
Шук тамчылар коелды.
Шатлыгыннан кош сайрады,
Кояш чыкты ялтырап.

**Ап-ак томан җиргә ятты**
**Иртә таңнан, ял сорап.**
Әнә салават күпере –
Ал, кызыл басмалары,
Гүя ул нәни кызларның
Чәчүргеч тасмалары.

(*Эльмира Шәрифуллина*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)** ________________________________________________

2.2. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**
________________________________________________________________

2.3. Фигыльдән ясалган исемнәрне күчереп языгыз. **(2 балл)**
________________________________________________________________

2.4. ***Кызыл*** сыйфатын дәрәҗәләр белән төрләндереп языгыз. **(2 балл)**
________________________________________________________________

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләнең хәбәрен языгыз. **(1 балл)**
________________________________________________________________

3. **“Җәйге яңгыр”** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________